Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Байлангар авыл башкарма комитеты

КАРАР

23 ноябрь 2021 ел №30

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл жирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл жирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл жирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл жирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 26 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 һәм 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле регламентта кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслы система һәм «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән тәгәл яраштырып файдаланыла.»;

1.2. 1.5. пунктының 11 – 17 абзацларын 3 – 9 абзацлары дип санарга;

1.3. 2.6.1. пунктының 4 – 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның жирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга»;

1.4. 2.6.1. пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә Башкарма комитет яки муниципаль район жирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга»;

1.5. 2.6.4. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның жирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл жирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка житкерелгәннән) соң үз көченә керә.

Жирлек башлыгы И.Ф. Каримуллин